ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы,
422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

02.12.2024 № 02

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы? -Татар Макылы авылындагы торак пункт территориясен төзекләндерү, дигән сорау буенча 2024 елның 29 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 113 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 82 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 82 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен тавыш бирде - җыенның 0 катнашучысы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы? - Татар Макылы авылындагы торак пункт территориясен төзекләндерү, дигән сорау буенча караны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгына Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: П.Е. Карпухин